Хәмидуллина, Р.  Урындыктагы ак яулык / Р. Хәмидуллина // Гыйбрәтханә. – 2025. – №3 (99). – Б. 8-10.

*Юлымда очраган һәркемгә рәхмәтлемен. Берсеннән-берсе гыйбрәтле язмышлы шәхесләр. Күңелләре көр, чиста, зарлануны белми, гел яхшылык өләшүче, яктылык сибүчеләр.*

# Урындыкта ак яулык



Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче Илгиз абый Хаҗиев гаиләсен  беләм мин. Хатыны Гөлфирә апа Яшел Үзән районы Акъегет авылыннан иде. Ләкин Гөлфирә апага Ходай тарафыннан гомер кыска бирелгән булып чыкты, бер ел элек ул, мәңгелек йортына күчте. Ул  Илгиз абыйның туган авылы Зәй районы Югары Шәпкә зиратында җирләнде.

Югары Шәпкә авылында Гөлфирә апа рухына багышлап җыелган мәҗлескә баргач, Илгиз абыйның әнисенең сеңлесе Мәдинә апа белән таныштым. Сөйләшеп сүзләр бетмәде, аның тормышы турында күбрәк белергә теләдем.

Мәдинә апа тумышы белән Сарман районының Шыгай авылынан булып чыкты. Авылда башлангыч мәктәпне тәмамлаган, аннан Теләнче Тамак мәктәбендә белем алган. Ул елларда тирә-күрше авыллар барысы да шунда йөреп укыганнар. «Мәктәптә ничек укыдың, Мәдинә апа» дигән сорадым. Мәдинә апа

- Яхшы билгеләр генә алып укыдым. Яңа Бүләктән Илһам Шакиров та безнең класста укыды. Ул бик моңлы итеп җырлый иде. Мәктәптә дүрт сигезенче класс укыдык. Илһам башта - «Д» классында иде. Классларны берләштергәч, аны мин укыган «Б» классына күчерделәр. Ул елларда ачлыгы, ялангачлыгы да булды бит. Барыбыз да бертөрле гаиләдән идек. Яшь чаклар булганга клубка да барасы килә иде. Бер очрак күңелемдә калган. Аякка киеп төшкән галошларны, буталмасын диеп, клубта төреп куя идек. Берзаман минекеләрне Илһам кигән бит. Шундый кечкенә галушны ничек сыйдыргандыр? Илһам галошның артын ерткан булып чыкты. Мескенкәем, аның шулкадәр борчылганын хәтерлим. Ачуланмадым инде, шулай бетте. Илһам озын тәнәфесләрдә җырлый иде. Җырлыйсы килсә дә, килмәсә дә, җырлаттылар инде аны. Тавышы яшьтән үк матур, шәп иде, – дип сөйләп алды.

Мәдинә апаларның аталары да  Илһамның абыйның әтисе кебек,  репрессия корбаны була. «Халык дошманы балалары» тамгасын таккан балаларга мәктәптә дә караш үзгә була шул.

– Мин яшь булганмын, кешеләрнең рәнҗеткәнен бик хәтерләмим, әллә инде онытылган. Ә менә Әкълимә апам гел искә ала иде... Апаның «Бервакыт мәктәптә борчак ашы бирделәр, шуны ашарга җыенып утырганда, алдымнан ашымны алып киттеләр... Мәктәптә төрле укытучылар бар иде шул» дип сөйләгәнен хәтерлим. Әкълимә апаның рәнҗетелүләре күңелендә гомер буена саклаган, күрәсең, - дип искә алды ул чакларны Мәдинә апа.

Мәдинә апа авылдашларын аклау җаен да тапты.

– Шыгай авылы халкы безнең гаиләне, әнкәйне дә, мине дә, бик хөрмәт итеп яшәделәр. Гаиләбезне көтү чиратыннан азат иттеләр. Җыелышта кайсыдыр рәхмәтле бәндәсе: «Хәдичә апаның бер сыеры гына бар, ул көтү көтмәсен», – дигән. Шыгай халкының һәрбарчасына мең-мең рәхмәтлемен - ди Мәдәни апа.

Мәдинә апаның әтисе алдынгы фикерле, абруйлы кеше була. Шушы тырыш гаиләдә 1936 елның 8 мартында дөньяга килә ул.

– Кызым, син тугач, әтиеңнең сөенгәнен белсәң... 8 март баласы бит син диеп сөя иде әни. Иң бәхетле бала булырсың әле! Син тугач, атаң бала юрганы, зур курчак, егерме метр ситса, ярты капчык дөге, шикәр күтәреп кайтты. Ул вакытта юк еллар бит, кайдан юнәткән, кайдан алгандыр? – дип, Мәдинә апа әнисе сөйләгәннәрне хәтеренә төшерде.

Гаиләдә биш баладан өч малай озак яшәмиләр, үләләр.

– Бүгенге көндә үзем генә калдым инде, барысы да мәрхүмнәр, – дип көрсенеп куйды Мәдинә апа. Әтием – репрессия корбаны. Аны 1936 елның 20 октябрендә аны кулга алалар һәм 3 ноябрьдә Минзәлә төрмәсендә атып та үтерәләр. Без моны соыннан гына белдек. Әнием гомере буе әтине көтеп яшәде. Һәрвакыт аның урындык башында ак яулыгы белән алъяпкычы эленеп торды. Капкадан кем генә керсә дә, шуларны алып бәйләп, йөгереп чыга иде. Вафатына кадәр әтинең үлеменә ышанмады, кайтып керер дип көтте. Шул уйлары белән җитмеш яшендә бакыйлыкkка күчте.

– Алабуга культура-агарту техникумына керү – язмышымның тагын бер борылышы, – дип искә алды Мәдинә апа.

Аның бу техникумда укуыын ишетү минем өчен матур хәбәр булды. Чөнки мин үзем дә шул уку йортын тәмамладым бит.

Мәдинә апаның мәктәптән соң укуын дәвам итү теләге зур була. Алабуга медицина училищесына керәсе килә. Ләкин, документлар тапшырырга мөмкинлеге булмый. Ә аларны ничек булса илтергә кирәк. Мәдинә апаны Лотфрахман исемле егет озаткалап йөри торган була. Беркөнне егет: «Минем сиңа яхшылык эшлисем килә. Әйдә, документларыңны үзем илтеп тапшырам», – ди. Мәдинә егеткә ышанып, документларын биреп җибәрә.

Имтихан бирергә баргач, медицина училищесында документлары булмый. Егетне эзләп культура-агарту техникумына барса, документлары шунда. Ул техникумга керү имтиханнарын бик яхшы тапшыра. Әмма соңыннан кабул итү комиссиясенә медицина училищесына керәсе килүен әйтә, документларын кире сорый. Кая инде ул, бирмиләр. Әле нинди бүлеккә диген, хоровой факультетына, балалайка белгечлегенә. Шулай итеп, 1952 елда Мәдинә культура-агарту техникумы студенты булып китә.

– Минем белән бергә Чаллыда гомер буе укытучылыкта эшләгән Һаҗәр дә укыды, -ди танышым. Һаҗәр Фәрдиевна исеме минем өчен якын. «Беләм мин аны, 25 нче мәктәптә эшләде», – дип куйдым. Яхшы укучы буларак Мәдинә апага төрле бәйрәмнәрдә байрак күтәреп йөрү бәхете дә тия.

– Ул вакытларда укытучылар гадел, игътибарлы иделәр, дип сөләде танышым. – Шәрәфетдинов Равил, Лариса Гаязовна, Насыйбуллиннар бар инде. Дежур кеше һәркөнне иртән кайнар су алып менә, бушлай биш тиенлек соры булка алып киләләр. Аларны ишек төбенә куялар. Ник берсе икене алсын, калса калды, ләкин икене алган

кеше булмады. Аны шул кайнар су белән ашап җибәрә идек. Тәмнәре әле дә тел очымда. Көндез үзебез пешерергә тырыша идек. Плитәгә чират инде. Укудан буш вакытларымда челтәр бәйли идем. Ял көннәрендә базарга алып чыгып сатам. Акчаның яртысына, тагын челтәр бәйләр өчен кәтүк, икенче яртысына бәрәңге, кием-салым алам. Югары стипендия алып укыдым. Гади стипендия ундүрт сум булса, югарысы егерме сум иде. Шушы акча яшәүгә, кирәк-ярагыма җитеп барды.

Мәдинә апа ике катлы тулак торакта яши. Соңгы курсларда фатирга күчә. Авылга кайтып йөрергә тырыша. Мәдинә апа авылга бик интегеп кайтканнарын хәтеренә төшерде:

– Паромга җитешергә теләп йөгерәбез, тирләп-пешеп салкын паромга килеп керәбез. Юллар начар, кайда ат, кайда машина белән кайтабыз. Яз көне Кама аша чыкканда, боз белән агып киткән вакытлар да булды. Безне Мәскәүдән килгән укытучылар да укытты. Роза Ивановна исемлесе бар иде. Һаҗәр белән икебезне, техникумнан соң, Мәскәүгә югары уку йортына имтихансыз алырга дигән карар да чыгардылар. Ул кәгазьдә общежитие адресы, бүлмә саннарына кадәр язылган иде. «Уку - техникум хисабыннан, шушы уку йортына укытырга кайту шарты белән диелгән документ авылга килде. Әнкәй: «Әй, кызым, сыерны сатсам инде», – диеп куйды. Мин, әнкәйне сыерсыз калдырмыйм инде диеп, бармадым.

Мәдинә апа Сарманга «Изба читальный»га кайта. Ул елларда яшьләр бик актив. Спектакльләр куялар, бәйрәмнәр, кичәләр үткәрәләр. Авылларга да чыгалар. Сарманда озак эшләргә туры килми. Әнисе авырып китә дә, аны карарга авылга кайта. Әнкәсенең сәламәтлеге бераз җайлангач, янәдән эшкә урнашырга теләп, мәгариф бүлеге мөдире Асия апа Мәрдәновага килә. Аны Нөркәй клубына эшкә җибәрәләр. Менә шул авылда гармунчы Котдус белән танышып, кияүгә чыга. Мәдинә апа гаиләсе турында:

– Минем ирем бик әйбәт кеше булды, гел ярдәм итеп торды. Әткәй-әнкәй дә эшемне хөрмәт иттеләр. Клуб хезмәткәрен беләсең инде: кеше ял иткәндә дә, бәйрәмдә дә эштә. Бу эштә аңлашып эшләми булмый. Әнкәй: «Эшләгән җиреңдә, кызым, хезмәтеңне күрсеннәр, ат та гомере буе эшли », – ди торган иде. Кайда гына эшләсәм дә, хезмәтемне тиешенчә бәяләделәр, – дип сөйли.

Мәдинә Әхмәтшинаны район Советы депутаты итеп тә сайлыйлар. Казанга съездларга бара.Шул еллардагы бер истәлеге белән дә уртаклашып алды ул:

– Сарман китапханәсендә Галимә апа эшли иде. Галимә апа белән мине Казанга делегат итеп сайладылар. Безне алып китү өчен Сарманга махсус самолет төште. Бу район өчен көтелмәгән хәл иде. Сарманнан – безне, Бөгелмәдән ике кешене алдылар. Шулай итеп, Казанның Опера һәм балет театрында съезд эшендә дә катнашып кайттык. Клуб эшен яратып эшләдем, иптәшем белән бергә бардык, бергә кайттык. Башта мотоцикл белән йөрдек, аннан авылда беренчеләрдән булып машина алдык. Соңрак балалар бакчасында урын бушады, берсе артыннан икенчесе дигәндәй, өч малай таптым. Аннан балалар бакчасына мөдир булып күчтем, – диде ул.

Мәдәният хезмәткәре булу бик ярап куя. Балалар бакчасы гел алдынгылар рәтендә була. РОНО җитәкчесе Марс Антипов абый аны: «Молодец, Әхмәтшина» диеп, гел үстереп эшләтә. Мәдинә апа пенсиягә дә шуннан чыга.

Әтисе турында тулырак беләсем килеп, сораулар бирдем.

– Әтиемне белмим шул, бары тик 1895 елгы булуын гына беләм. Мин әтиемнең күчтәнәчен әле дә булса алып торам. Репрессия корбаннары көнендә, авыл советы ел саен бүләкләр китерә. Быел да килделәр. Быел 89 яшемне тутырам, шушы яшемдә дә этием мәрхүмкәемнең күчтәнәче килеп торсын инде, ә? Әнкәем бик тырыш кеше иде. Гомер буе сыер асрады. Сыеры булган гаиләләр ачлык елларында интегеп яшәмәде. Эшләп үстек, сыер саудык, сөт- катыктан аерылмадык. Әнкәй еш кына аш-су мәҗлесләре үткәрде. Пермьдә Гайсә исемле абыйсы яшәде. Әнкәй, абый кайтуга диеп, тәкә, сарык симертә. Кунаклар бик зурлап кайталар. Өчәр чемодан, һәркемгә бүләк: кием-салым, без күрмәгән кәнфит-прәнникләр. Күрше-күләнгә тастымаллар алып кайтып өләшәләр иде. Әнкәй бөтен авыл халкын диярлек җыеп, аш үткәрә. Өйгә зур итеп өстәл әзерлибез. Түбән, югары табын була торган иде. Югары табынга – абыстайлар, гыйлемле кешеләр, ә түбәненә күрше-күлән утыра. Ризыгы да башта югары табында, аннан, түбән табынга төшә иде. Мәҗлескә башта – ирләр, аннан хатыннар киләләр. Гайсә абый белән хатыны авыл кешеләрендә кунактан-кунакка ашка йөреп, янәдән Пермьгә кайтып китәләр иде. Бер хәл исемә төште. Өйдә шулай кунак ашы үткәрәбез. Әнкәй миңа тавык оясыннан йомырка алып керергә кушты. Чыктым, дүртме, бишме йомырка алып кердем. Аштан соң, әни ул йомыркаларны тавык асрамаган кешеләргә хәер итеп биреп җибәрде. Сары май салып, тары бәлеше пешерә торган иде. Ул заманнарда дөге, карабодай ярмалары кибетләрендә юк. Кеше ашап бетереп китми, ризык кала. Иртән эшкә киткән уникеләп сыер савучыны көтеп торып, чәйгә чакабыз. Рәхмәтләрен әйтеп, сыйланып чыгалар иде. Әле хәзер дә авылга кайтсам, әнкәйне искә алып « Хәдичә апаның тары бәлеше тәмнәре әле дә онтылмый, андыйны бүтән бер җирдә дә ашаганым юк» дип, әйтүчеләр бар.. Әнкәй яшелчә бригадиры булып эшләде. Ул вакытта колхозда кыярын да, помидорын да, гомумән, нинди яшелчә бар, барын да утырттылар. Нөркәйләр Шыгай аша үтеп йөриләр иде. Әле аларның «Шыгай яшелчәлегендә бер әйбәт апа бар, без аннан бер-ике кыяр сорыйбыз, ул безгә, чиләге белән бирә» дип әйткәннәрен хәтерлим, – дип сөйләде ул.

Мәдинә апа Нөркәй авылына килен булып төшә. Мәдинә апаның Шыгайда үзе генә яшәп калган әнисенең соңгы елларда хәле авырая. Мәдинә апаның аны үзеләренә алып киләсе килә. Бу вакытта алар кайната, кайнана, кайнатасының сеңлесе белән бергә яшиләр. Ир-ат белән бик аз гына торып калган Хәдичә апа «Сездә ирләр күп, кызым, кода бар, малайлар» дип, тиз генә ризалашмый. Ишек алларына Мәдинә апа килен булып төшкән иске өй сүтелмәгән була. Гаиләдәгеләр белән сөйләшкәч, өйне җыештырып, җылытып, Хәдичә апаны шунда алып кайталар.

– Әнкәемә Аллаһның рәхмәте яусын, хәер-догасын калдырып китте, – ди Мәдинә апа. – Кайнана, кайната да юк инде, алар да мәрхүмнәр. Олы улым хәзер дә «Әни, әби белән бабай сиңа ни өчен рәхмәт укый иде ул?» дип сорап куя. Кайнанам да һәрвакыт: «Аллаһның мең-мең рәхмәте яусын, балакаем» ди торган иде.

Кайната белән кайнана намазларын калдырмыйлар. Хәдичә апа да кызына кечкенәдән Коръән сурәләрен өйрәткән була.

– Әлхәмдүлилләһ, шөкер, – ди Мәдинә апа. – Раббым, ничек ярдәмн биреп яттан өйрәтте икән? Ничек укыганымны, кайчан ятлаганымны да хәтерләмим. Бүгенге көндә, шушы яшемдә дә бер тукталышсыз «Иман»ны яттан укып чыгам әле.

Мәдинә апа әнисе әйткән сүзләрне кайтып-кайтып исенә төшерә:

– Кызым, кода намаз укыганда, азан әйткәндә, тыштан утын күтәреп керә торган булсаң да, кайда ишетәсең, шунда туктап кал. Ишектән атлап кергән чагың булса, коданың укып бетергәнен көт, аннан соң гына утыныңны урынына илтеп сал, – дия торган иде.

Кайнатасы Гариф абзый яшьләргә никах укып, балаларга исем кушып, мәрхүм булганнарны соңгы юлга озатып йөрүче карт була. Карчыгы үлгәннән соң, 94 яшенә кадәр ул улы һәм килене кадер-хөрмәтендә яши.

Мәдинә апа балаларын да тәүфыйклы, мәрхәмәтле булсыннар диеп үстерә. Уртанчы малае әтиләренең күршесендә ялгызы яшәүче Гөлмениса апаны үзләренә алып тәрбияли. Гөлмениса апа 102 яшькә кадәр яши. Әле өченче ел гына авылга алып кайтып җирлиләр.

Мәдинә апаның да намазга басасы, бик укыйсы килә. Ул 3-4 яшьлек вакытта әнисе өйрәткән «Фатиха», «Ислах»сүрәләрен искә төшерә. Калганнары да күңелендә сакланган. Бүгенге көндә биш вакыт намазын калдырмый. Үзеннән алты яшькә олырак ире Котдус бу вакытта әле намазда булмый. Ул да яшьтән әтисе артыннан догалар укырга өйрәнгән, аның белән намазга да йөргән. Мәдинә апа:

– Котдусым минем белән ураза тота башлады, Мәрхүмкәем үрдәк итен бик яратты. Аны ашасаң карын да ачмый, ди, торган иде, – дип искә алды.

Иптәшенең дә намаз укыйсы килә. Китаптан укырга да күзләре начар булса да, аптырап калмый, «Әйдә, син укы, мин кабатлыйм» дип, Мәдинә апа артыннан кабатлый-кабатлый, өч көн дигәндә «Әттәхият» догасын ятлап та куя.

Котдус абзыйның вафатына унөч ел үтеп китән инде. Олы уллары Илдус, пенсиягә чыккач, авылга кайтып, матур итеп йорт салып керә. Рәис гаиләсе белән – Чаллыда, төпчеге Ришат күрше авылда яши. Алар, әниләре янына кайтып, ул яшәгән йортны яңартып торалар.

Мәдинә апа иптәше белән 52 ел бергә яши.

– Ә ничә яшьтә кияүгә чыктың? – дип сорадым.

Ул елмаеп:

– Әй, кем белгән инде аны... Бер елны малайлар, килennәр кайтып керделәр дә: «Сезнең бит бергә яши башлавыгызга 50 ел тула», – диделәр. Шул уңайдан балалар, оныклар, туганнар белән җыелышып, Коръән ашы уздырдык.

Үзем дә гомеремне мәдәнияткә багышлаган кеше буларак, Мәдинә апаны тыңлау миңа рәхәт иде. Аңа саулык-сәламәтлек телим, балалары, килен, оныклары җылысын тоеп яшәргә насыйп булсын дигән теләкләрдә калам. Ачык күңелле, күзләре генә түгел, йөзе балкып торган, яхшы хәтерле, матур аһәңле тавышлы бу апа белән тагын да очрашырга язсын.

Роза Галимулла кызы ХӘМИДУЛЛИНА,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Яр Чаллы шәһәре